| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**РУКОВОДИТЕЛЬ**<br>**Исполнительного комитета**<br>**Кадряковского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Кадрәк авыл җирлеге**<br>**Башкарма комитеты**<br>**ҖИТӘКЧЕСЕ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.10.2019 Кадрәк авылы № 2

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадрәк авыл җирлеге Кадрәк авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кичкетан авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадрәк авыл җирлеге башлыгы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадрәк авыл җирлеге башлыгы к а р а р б и р д е:

1.2019 елның 19 октябренә Кадрәк авылы мәдәният йорты бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 14 сәгатькә билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга: «I группа инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән кешеләрдән (80 яшькә җиткән), торып укучы студентлардан тыш, Кадрәк авыл җирлегендә теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2019 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә юнәлтергә Сез ризамы:

1. Кадрәк авылы зиратын төзекләндерү.
2. Кадрәк авылының Ленин, Сосновая, Кыр, Заречный урамнарына вак таш җәю һәм чокырларны ямау.
3. Кадрәк авылының Заречная, Ленин урамнарындагы күперләрне ремонтлау.
4. Кадрәк авылы урамнарын кардан чистарту.

5. Урамнарны яктырту, лампаларны һәм контроль приборларын алыштыру.

6. Янгын сүндерү машинасын карап тоту, ремонтлау, янгын сүндерү машинасын йөртүчегә хезмәт килешүе буенча түләү, электр белән тәэмин итүнең автоном чыганагын сатып алу.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3.Кадрәк авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыру һәм үткәрүне йөкләргә.

4.Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында.бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

А.А.МИХАЙЛОВ